ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.03.2020 ел Баулы шәһәре №39

Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 2012 елның
1 февралендәге 28 номерлы карары
(2019 елның 12 августындагы 230
номерлы карары белән кертелгән
үзгәрешләр белән) белән расланган
Татарстан Республикасы Баулы
муниципаль районы мәнфәгатьләрендә
ачык сервитутлар билгеләү һәм
туктату тәртибенә үзгәреш кертү турында

«Җирләрне мелиорацияләү турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына агролесомелиорация үткәрүне хокукый җайга салуны камилләштерү елешендә үзгәрешләр кертү хакында»гы 2019 елның 27 декабрендәге 477-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 1 февралендәге 28 номерлы карары (2019 елның 12 августындагы 230 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәнфәгатьләрендә ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.3 пунктның 3) пунктчасында "дренажлы" сүзеннән соң “мелиорация технологияләре" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны "Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы" МКУ җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гозәеров